РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» декабрь 2022г. г. Альметьевск № 188

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 10 августындагы 83 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен бүләкләү һәм башка естәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Хезмәткәрләрне системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, шулай ук район җирле үзидарә органнары коллективларында сәламәт яшәү рәвеше традицияләрен булдыру максатында,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 10 августындагы 83 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен бүләкләү һәм башка өстәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 06 октябрендәге 129 номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 146 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 243 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 313 номерлы, 2019 елның 30 сентябрендәге 324 номерлы, 2021 елның 22 июлендәге 62 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 90 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 149 номерлы, 2022 елның 31 октябрендәге 173 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карарга 1 нче кушымтада:

а) 1 бүлекнең 1.5 пунктындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- һөнәри эшчәнлекнең югары нәтиҗәлелеге һәм/яисә теп вазыйфаи бурычларга карамый торган йөкләмәләрне сыйфатлы үтәве өчен бер мәртәбә бирелә торган премия өчен - муниципаль хезмәткәрләр өчен бер вазыйфаи хезмәт хакыннан ике айлык акчалата хезмәт хакына кадәр һәм муниципаль бурычны биләүче затлар өчен бердән алып ике айлык акчалата хезмәт хакына кадәр (3.1 пунктының унбишенче абзацыннан һәм 3.3 пунктының уникенче абзацыннан тыш, спорт ярышларында призлы урыннар белән шөгыльләнү, шулай ук аларда катнашу өлешендә)».

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре

Спартакиадасы программасына керә торган һәрбер аерым спорт төре өчен призлы урыннар биләгән өчен премиянең түбәндәге күләме билгеләнә:

1 урын өчен - 80 460 сум;

2 урын өчен - 57 472 сум;

3 урын өчен - 34 483 сум;

Моннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре Спартакиадасы ярышларында катнашкан өчен 57 472 сум күләмендә премия билгеләнә.»;

б) 3 бүлекнең 3.1 пунктындагы унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-ярышларда, конкурсларда һәм спорт, мәдәни, фәнни һәм башка юнәлешләрдәге башка чараларда призлы урыннар алу, шулай ук аларда катнашу;»;

в) 3 бүлекнең 3.3 пунктындагы уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- ярышларда, конкурсларда һәм спорт, мәдәни, фәнни һәм башка юнәлешләрдәге башка чараларда призлы урыннар алу, шулай ук аларда катнашу;»;

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Н.В. Парфилова).

Муниципаль район Башлыгы — Т.Д. Нагуманов

•СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА•